**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 ел «27» декабре** **№ 16-53**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы территориясендә «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен» раслау турында» 2012 елның 24 декабрендәге 18-60 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 30 статьяның 1.2 пунктын җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрларын түбәндәге редакциядә укырга:

- бер фатирга 400 кв.м торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы; максималь 2500 кв.м. ( элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- яшелчәчелек өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 400 кв.м; максималь 2000 кв.м. ( элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 400 кв.м; шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның бер үк вакытта милек хокукында һәм (яисә) башка хокукта булырга мөмкин җир кишәрлекләренең гомуми мәйданының максималь күләме ике гектарга тигез, шул исәптән торак пункт чикләрендә - бер гектарга; ( элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң чик күләмен түбәндәге редакциядә укырга:

- торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 400 кв.м; максималь 2500 кв.м. ( элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы адресы буенча урнашкан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә (бастырырга). Яңа Чишмә ав., Ленин ур. 44, 48а.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Яңа Чишмә авыл җирлеге башлыгы** **В. М. Козлов**